**КАРАР**

**«13» ноябрь 2025 года** **№ 10**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“Ачык хакимйятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принөиплары турында” 2025 елның 20 мартында 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 204 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үктәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде :

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирле-ге Урта Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тэшкил иткэн, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлның буй профилен төзәтү; кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)
- урамнарны яктырту җайланмасы (баганаларны сүтү һәм монтажлау, урамнарны яктырту өчен чыбыклар сатып алу; яктырткычлар сатып алу)
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү (һәйкәлне бер урыннан икенче урынга демонтажлау һәм монтажлау һәм аны төзекләндерү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау бркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 101 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 55 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

“Эйе” позициясе өчен халык җыенында катнашкан 55 кеше тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылы халкы җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирле-ге Урта Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлның буй профилен төзәтү; кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)

- урамнарны яктырту җайланмасы (баганаларны сүтү һәм монтажлау, урамнарны яктырту өчен чыбыклар сатып алу; яктырткычлар сатып алу)

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү (һәйкәлне бер урыннан икенче урынга демонтажлау һәм монтажлау һәм аны төзекләндерү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Инернет мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә, Арча муниципаль районның рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков